ӨЗЕЛМӘСЕН ТЕЛ!

Татар авылында татар баласының русча сөйләшә башлавы ул – соңгы кисәту

> 2

ТУГРЫЛЫК БӘЙРӘМЕ

Үрнәк гаиләләрдән бәхетле тормыш серен белештек

> 3

ЯХИННАРГА АЛМАШКА

Татарның музыка сәнгате ни хәлдә?

> 3

ХӘЕРЛЕ ЮЛ!

«ВТ» хәбәрчесе «Ефәк юлы»нда ярышучыларны Лаешта озатып, Мамадышта каршы алды

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 96 (29063) | Шимбә | 8 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

УРТАК БӘЙРӘМ

Авыл хуҗалыгы

Бу көннәрдә «Казан Экспо» янында авыл хуҗалыгы тармагының иң көтеп алынган зур чарасы – «Бөтенроссия кыр көне – 2023» күргәзмәсе гөрләде. 40 гектарга сузылган мәйданда авыл хуҗалыгы өлкәсенең төрле юнәлешендә аграр күргәзмә оештырылган иде. Күргәзмәдә бөртекле культураларның яңа сортларын, Россиядә чыккан агротехника, фермерлар продукциясе белән танышу мөмкинлеге булды.

tatarstan.ru

Әйтик, Agrida Чувашия компаниясе сөт комплекслары өчен суыта торган җилләткечләр тәкъдим итте. Әлеге технология эсседә сыерларда стресс булмасын өчен кулланыла икән. Сынау участогында ике йөз сиксәннән артык бөртекле, азык, техник, майлы культуралар үрнәкләре тәкъдим ителгән иде.

Аграрийлар, эшмәкәрләр, район башлыклары, эре агрохолдинг җитәкчеләре эшлекле сөйләшүләр алып барганда, үзара тәҗрибә уртаклашканда, гади катнашучылар мини-Сабан туенда, гастрофестивальдә, мастер-классларда һәм күп төрле күңел ачу чараларында катнашып, бушлай туңдырма белән сыйланды.

Масштаблы чараның беренче көнендә җир сөрү буенча X ачык Россия чемпионаты ачылды. Монда Россиянең 40 төбәгеннән һәм Белоруссия, Кыргызстан, Казахстаннан килгән 65 иң яхшы механизатор катнашты. Чемпионатта катнашучылар «Трактор-шоу» ярышында беренче тапкыр Кытай тракторларында (ZOOMLION) үз осталыкларын күрсәтә алды. Аның ачылышында Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин, Россия авыл хуҗалыгы министры урынбасары Елена Фастова катнашты.

Алексей Песошин кунакларны Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исеменнән сәламләде.

– Агросәнәгать тармагын үстерү Татарстанның социаль-икътисадый сәясәтенең стратегик өстенлекләренең берсе булды һәм шулай булып кала да. Агросәнәгать комплексында ундүрт меңнән артык кеше эшли. Без авыл хуҗалыгы хезмәткәрләрен югары профессиональлек, эшкә җаваплы караган өчен кадерлибез һәм хөрмәт итәбез, аларда камилләшү омтылышы булу белән горурланабыз, – диде Алексей Песошин.

Моннан тыш, сөт юнәлешендәге терлекләрне билгеләү буенча Бөтенроссия конкурсының беренче этабы узды. Әйтергә кирәк, ил дәрәҗәсендә мондый чара беренче тапкыр уздырылды. Бәйгедә 52 хуҗалыктан токымлы 80 сыер катнашты.

Кичә исә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Россия авыл хуҗалыгы министры Дмитрий Патрушев һәм Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев күргәзмәне рәсми төстә ачты. Дмитрий Патрушев Россия Президенты Владимир Путинның сәламләвен укыды. Дәүләт башлыгы сүзләренчә, күп еллар дәвамында колачлы күргәзмә илнең төрле төбәкләреннән агросәнәгать комплексы хезмәткәрләрен берләштерә. «Аның бай программасы катнашучыларга эшлекле, конструктив рәвештә актуаль һөнәри проблемалар турында сөйләшергә, тәҗрибә уртаклашырга һәм иң яхшы практикалар белән уртаклашырга мөмкинлек бирә. Илебезнең агросәнәгать комплексының игенчелек һәм терлекчелек тармакларында инновацион аграр технологияләрне, искиткеч казанышларны күрсәтергә дә», – дип ассызыклаган Владимир Путин.

Рөстәм Миңнеханов Дмитрий Патрушевка Казанның Бөтенроссия кыр көнен уздыру урыны итеп сайлаганнары өчен рәхмәт белдерде. Ул ассызыклаганча, катнашучыларның һәркайсы монда үз җитештерүен үстерү өчен кызыклы тема табачак. Мәсәлән, экспертларны тыңлау һәм яңа танышулар булдыру өчен эшлекле программа – 25тән артык чара мөмкинлек бирә.

– «Бөтенроссия кыр көне» – һөнәри тармак өчен генә түгел, ә авыл һәм шәһәр халкы өчен дә уртак бәйрәм. Бу мәйданчыкта бик кызыклы әйберләр бар. Барлык катнашучыларга да эшебезнең шундый күркәм һәм файдалы вакыйгаларга бай булуын телим, – диде республика Рәисе.

Шуннан соң Рөстәм Миңнеханов белән Дмитрий Патрушев тәҗрибә кырларында һәм күргәзмә участокларында тармак казанышларын бәяләделәр. Кунаклар шулай ук тракторларда экстремаль ярышларны карадылар һәм күргәзмәдә катнашучылар өчен оештырылган Сабан туендагы татар ишегалдында булдылар.

Пленар утырышның төп темасы – үсемлекчелек иде. Шуңа күрә чыгыш ясаучылар сыйфатлы орлыклар белән тәэмин ителеш, тукландыру, мелиорация, уңдырышлылык мәсьәләләренә зур урын бирде. Дмитрий Патрушев та узган ел җыеп алынган мул уңышның җиңел генә «күктән төшмәве»нә басым ясады.

Ахыры 2 нче биттә >

Күбрәк бирә башлыйлар

Авыл ипотекасы («Сельская ипотека») буенча ташламалы кредит күләмен арттырганнар. Программада катнашучыларның барысы өчен дә (кайсы төбәктә яшәүләренә карамастан) 3 процентлы кредитның иң зур күләме 3 миллионнан 6 миллион сумга җиткерелгән.

Шулай итеп, йортны әзер материаллардан үз кулларың белән төзү өчен, шулай ук зур авыл-бистәләрдә биш каттан биегрәк булмаган күпфатирлы йортлардан торак сатып алу өчен ташламалы ипотека рәсмиләштерергә мөмкин.

Премьер-министр Михаил Мишустин әйтүенчә, төбәкләрне үстерү өчен бик мөһим чара бу. Ул авыл җирләрендә яшәүчеләргә тизрәк торaклы булуга һәм аларга белгечләр җәлеп итүгә этәргеч бирәчәк.

Исегезгә төшерәбез: Татарстан авыл ипотекасын бирү күләме буенча Россиядә лидер төбәкләр өчлегенә кергән. Узган елның декабрь ае мәгълүматларына караганда, республикада барлыгы 7,1 миллиард сумлык 3 меңнән артыграк кредит бирелгән. Программа 2020 елда тормышка ашырыла башлады.

Поши килеп чыкмасын!

Татарстан юлларында кыргый хайваннарның килеп чыгу очраклары арткан. Биоресурслар буенча дәүләт комитеты хәбәренә караганда, соңгы вакытларда Баулы, Биектау, Алабуга һәм Түбән Кама районнарында 7 шундый очрак теркәлгән. Бигрәк тә пошилар һәм кыр кәҗәләре көпчәк астына еш эләгә икән. Шуңа күрә йөртүчеләрдән тизлекне тиешледән арттырмау, җәнлекләрнең килеп чыгу куркынычы турында кисәтүче юл билгеләренә игътибарлы булу сорала. Ведомствода билгеләп үтелгәнчә, кыргый хайваннар тыюлык, заказниклар яки урманнар тирәсеннән үткән юлларга күбрәк чыга. Шуңа күрә мондый урыннардан узганда аеруча сак булырга кирәк.

Җәнлекне бәрдергәндә яки юлда җәрәхәтләнгән, һәлак булган җан иясенә тап булганда, бу хакта кичекмәстән 112 телефоны аша хәбәр итәргә кирәк.

Ял кыйммәтләнә

Чит илләргә туристлык юлламалары бәясе, сум курсы күпмегә артса, шуның кадәр кыйммәтләнә. Татарстан Туристлык агентлыклары ассоциациясе президенты Рамил Мифтахов «Татар-информ» хәбәрчесенә белдергәнчә, хәзер юллама хакы уртача 10–12 процентка үскән. Аның әйтүенчә, сумның курсы үзгәрү туристлык юлламаларына шундук йогынты ясый. Чөнки чит илләргә юллама бәясе евро яки доллар курсына бәйле.

Исегезгә төшерәбез: доллар курсы узган елның 22 мартыннан соң беренче тапкыр 92 сумга кадәр җитте, ә евро 100 сумнан артып китте.

Вазгыять һәм гамәл

Татарстан күпере

Чит илләр белән мөнәсәбәтләр урнаштыру буенча илебездә иң яхшы төбәкләрнең берсе! Казанга эш сәфәре белән килгән Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавров Татарстанга әнә шундый зур бәя бирде. Бу – иң беренче чиратта, республика башлыгы Рөстәм Миңнеханов башкарган эшкә хөрмәт билгесе, әлбәттә. Татарстан Рәисенең быел чит илләргә эш сәфәрләрен «ВТ» да барлады.

Рөстәм Миңнеханов Сергей Лавров белән Казан Кремлендә очрашты.

– Татарстанның тышкы хезмәттәшлеге үсешенә ярдәм күрсәтүегез өчен рәхмәт әйтәсем килә. Илебезнең бердәм тышкы сәяси юнәлеше кысасында республика дустанә илләр, хезмәттәшләр белән элемтәләрне ныгытуга үз өлешен кертә, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рәис чит илдә Татарстан вәкиллекләре эшләп килүен дә әйтте. Моннан тыш, республика Үзбәкстан, Казахстан, Азәрбайҗан һәм Төрекмәнстан белән ныклы элемтәләр урнаштырган. Рөстәм Миңнеханов Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча үзе җитәкләгән «Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме эшенә дә аерым тукталды.

Сергей Лавров быелның маенда Татарстан башкаласында узган «KazanForum»ны югары бәяләде. «Җыенга бәйле материалларны укыдым. Эш программасы бик тыгыз булган», – дигән фикер җиткерде министр.

– Сез – тышкы элемтәләр алып бару буенча илнең әйдәп баручы төбәкләренең берсе. Иң мөһиме – бу эш республикага да, гомумән, ил өчен дә яхшы нәтиҗә бирә, – диде Сергей Лавров.

Чарада Владимир Путин указы нигезендә киләсе елның көзендә Татарстан башкаласында узарга тиешле БРИКС илләре дәүләтләре (аңа Бразилия, Россия, Һиндстан, Кытай һәм Көньяк Африка Республикасы керә) башлыклары очрашуы турында да сөйләштеләр.

Казанда министр «Ефәк юлы» халыкара ралли ачылышы тантанасында да катнашты. Рөстәм Миңнеханов һәм Сергей Лавров ярышларда катнашачак техниканы карады, экипаж вәкилләре белән аралашты. Министр билгеләп үткәнчә, ралли Евразия киңлеген тоташтырган элеккеге сәүдә маршруты буенча уза. Татарстан «КамАЗ»лары зур юлга кузгалды, ә без Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге республика делегациясенең быел чит илләргә мөһим эш сәфәрләрен барлап чыктык.

Ел башында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ил делегациясе составында Россия – Төрекмәнстан бизнес форумында катнашты. Халыкара чарага кадәр Рөстәм Миңнеханов Ашхабадта Төрекмәнстан парламентының Югары палатасы – Милли Генгешнең Халык Маслахаты Рәисе Гурбангулы Бердымөхәммәтов белән очрашты. Гурбангулы Бердымөхәммәтов билгеләп үткәнчә, Россия – Төрекмәнстан мөнәсәбәтләре кысасында, Ашхабад Татарстан белән хезмәттәшлек итүгә зур әһәмият бирә. Казанда Төрекмәнстан генераль консуллыгы ачылу да ике арадагы элемтәләрне ныгыткан. Яклар кабат апрель аенда очрашты. Рөстәм Миңнеханов Төрекмәнстанга сәфәр кылды. Ашхабадта ул Төрекмәнстан Президенты Сердар Бердымөхәммәтов белән дә күреште. Анда хезмәттәшлекне киңәйтү турында фикер алыштылар.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Фаяз ХУҖИН, археолог, тарих фәннәре докторы, профессор:

Татар халкын саклау өчен дин, тел һәм моң кирәк, диләр. Иң әһәмиятлесе – милли үзаң кирәк. Аны тәрбияләүнең бер генә юлы бар – тарихыбызны яхшы белү. Үз тарихын белгәннәр генә горурланып «мин – татар» дип йөреячәк, туган телен өйрәнүгә дә теләк туачак.

(«Интертат»ка әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – БАЛАЛАР ЯЛЫ

Июньдә Татарстаннан 100 меңнән артык бала һәм үсмер лагерьда ял иткән. Бу – җәйге планның 61 проценты.

ХӘЗЕРГЕ ВАКЫТТА **180** ЛАГЕРЬДА

21979 БАЛА ЯЛ ИТӘ

Мобилизацияләнүчеләрнең балалары	301
Лисичанскидан килгән балалар	79
Мәктәп яны, хезмәт һәм ял лагерьлары	3000
Кара диңгез буенда	1125

Соңгысы түгел

6 июль көнне, глобаль җылыну сәбәпле, Җир шарында теркәлгән уртача һава температурасы рекорды (+17,23 градус) соңгысы түгел. Россия Гидрометеоүзәге фәнни җитәкчесе Роман Вильфанд әйтүенчә, яңалары да булачак.

Моңа кадәр быел июнь аеның, планетада мондый күзәтүләр башланганнан бирле, иң эссе июньгә әйләнүе турында хәбәр ителгән иде. Европаның көньяк-көнбатышында, Канада, АКШ, Мексика, Азия һәм Австралиянең көнчыгышында рекордлы температуралар теркәлгән. Шул ук вакытта узган айда АКШның, Россия һәм Австралиянең көнбатыш өлешләрендә гадәттәгедән салкынчарак булган.

Вильфанд әйтүенчә, белгечләрне әлеге яңалык әллә ни гаҗәпсендерми: бу климат үзгәрү тенденцияләренә тулысынча туры килә. «Әйтергә кирәк, биредә сүз температурадагы ниндидер бик кискен үзгәрешләр турында бармый: һава температурасы алдагы рекорд белән чагыштырганда 1 градусның йөздән бер өлешеннән генә югарырак булган. Якын киләчәктә безне яңа температура рекордлары көтә. Бәлки әле быел җәен дә булыр алар», – дигән ул.

Белгеч сүзләренә караганда, температураның артуы атмосфера һавасына төтен һәм газ чыгу сәбәпле глобаль җылынуга бәйле.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

СӘЯСӘТ ТОТСА ЯКАҢ, *яки Милләтчелек гөнаһмы?*

Татар менталитеты шундый, «милләтче» сүзен бездә артык куанып кабул итмиләр кебек. Миллилеккә битараф, манкорт карашлы кеше өчен андый зат – гомумән дә кычытмаган җирен кашып йөрүче бер тинтәк. Тик соңгы елларда өмет бары шул фидакарьләрдә генә түгелме? Яшисе, исән каласыбыз килгәндә милләтчеләр булырга, шулар ук йокылы-уяулы гавамны чеметкәләп, аның кайсы кавемнән икәнен искәртеп торырга тиеш түгелме?

Милләтнең аңлы өлеше – зыялы катлавы, пассив күпчелектән аермалы буларак, вазгыятькә сиземле. Милләтчелек, кемнәрдер милләтченең башын төеп торганда да, дәүләтсезлек шартларында гомерне озайту чарасы ул. Шунысын да искәртик: дәүләтсез халык милләтчесе, дәүләтле кавемнәрнекеннән аермалы буларак, һәрдаим саваплы, дөрес юлда. Андыйлар үз милләтен башкалардан өстен куймый, бары аны бәхетле һәм гомерле итәргә генә тели. Кешене үләсе килмәгән өчен гаепләп булмаган кебек, милләтне дә яшәргә тырышкан, фанилыкка ябышкан өчен гаепләп булмый бит. Азчылык дәүләт милләтчесенең зәңгәр хыялы – үз халкын башка халыклар белән, шул исәптән дәүләтле халыклар белән дә булдыра алган чаклы тигез итү. Мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, телен киләчәк буыннарга илтеп җиткерү. Аңарда милләтчелекнең явыз формасы булган шовинизм аз гына да юк, була да алмый. Без андый затларның кадерен белергә тиештер.

Бигрәк тә тел дип, милли мәгариф, дип гаҗизләнүчеләр сафы артмаганда, чын зыялылар сафы кимеп килгәндә. Татар мохите тарайганда. Ә ул чынлап та тарая. Төнлә саташып уянырлык хәл: инде авылларда балалар үзара русча сөйләшә. «Татар, уян, моның ише хәл бер дәвердә дә булмаган», – дип чәчрәп чыгучы күренми. Ниндидер программа төзү, хәлиткеч чаралар күрә башлауны әйтмим дә. Берсе дә юк!

Татар авылында татар баласының русча сөйләшә башлавы (үз авылымда үзем шаһит булсам да, тоташтан түгелдер дип өметләнәм) ул – соңгы кисәтү. Күп булса, тагын бер, ике буын… Бер буын озынлыгы – 25 ел, диләр. Болай барса, яңадан илле елдан милләт исәнлеген күпме дәверләр буе саклап килгән галиҗәнап татар авылы русчага күчәчәк. Бу – татар авылының, аның белән бергә татарның да бакыйлыкка, җәһәннәмгә юнәлүе дигән сүз. Нәкъ менә җәһәннәмгә. Милли горурлыгы, үзаңы сай булган, үзен яклый белмәгән кавем, кайбер акланыр сәбәпләр булуга да карамастан, оҗмахка өмет тота алмыйдыр ул.

Вазгыять бүген үк шундый, яңадан 10–15 елдан ук татар язучысы, шагыйре, композиторы, журналисты – барысы да үтә дә «штучный товар»га әйләнәчәк. Ул хәл бүген үк сизелә. Агым уңаена йөзү дәвам иткәндә, инкыйраз котылгысыз. Күз алдына китерү дә кыен: шул дәрәҗәдәге камил, бай тел, меңьеллык әдәбият, затлы мәдәният, кабатланмас җырлар гел булмагандай юкка чыксын әле. Моннан да олы югалту, фаҗига була аламы? Бу, чынга ашканда, татар өчен генә түгел, кешелек, дөнья мәдәнияте өчен дә зур югалту бит…

Дөнья, кешелек җәмгыяте бүген XVI гасырда яшәми: дөнья меркантиль булса да, анда гаделлек, шәфкать, гуманизм да юк түгел. БМО, ЮНЕСКО кебек оешмалар бар. Игелек, миһербанлык дигән категорияләрне дә буш сүз дип атап булмый. Флора белән фаунаны саклаучы кануннар, шул ук «Кызыл китап» бар. Төрле тарихи корылмаларны әнә ЮНЕСКО такталары беркетеп, кадерләп саклыйлар. Кече халыклар бәласен генә күрергә теләмиләр. Азчылык милләтләрне беренче чиратта алар яшәгән, алар гасырлар буе баеткан, дошманнардан саклаган ил, аның җитәкчеләре якларга һәм сакларга тиештер дә бит. Тик алай түгел шул.

Кайбер акланыр сәбәпләр бар, әлбәттә. Без биш гасырга (!) якын башкалар кулында яшәп тә, әлегә исән. Сәламәт түгел, тик исән. Дөрес, шул ук татар авылының исәнлеге үткән гасыр урталарына чаклы аерымланып яшәү – изоляция, кеше башына мәгълүмат ташкыны ишелеп тормауга бәйле. Мин үскәндә безнең олы авылда русча сөйләшүче юк иде. Телевизор бар кешедә дә түгел, ниндидер гаджетларның әле исе дә юк. Өлкән туган телен без рус теле һәм әдәбияты дәресләрендә һәм дә район үзәгенә баргач кына ишетә идек. Безгә чаклы яшәгән буыннар да шундыйрак шартларда гомер иткән. Совет чорында да ил халкының яртысы милләте буенча рус булмау дәүләт җитәкчелеген милли сәясәткә бик тә сак караттры. Бүген азчылыклар бар халыкның биштән берен генә тәшкил итә, вазгыять тә шул сәбәпле башка.

Сүз башы милләтчелек турында иде бит әле. Милләтче ул – сәясәтче. Дәүләттәге милли сәясәткә үз фикерен белдереп, аны бәяләп, халкына җиткереп баручы. Халык сәясәт белән кызыксынганда, актив булганда, бу эш җиңел башкарыла. Ләкин безгә нәрсәгә кагылсак та, югарыдан: «Мәсьәләне сәясәтләштерергә кирәкми, ярамый», – дип тукып тордылар. Азчылыкларга сәясәттән читләшү һәрчак зыянга. «Син сәясәт белән шөгыльләнмисең икән, сәясәт килә дә, үзе синең белән шөгыльләнә башлый, якаңнан каерып ала», – дигән, фәкыйрегез кабатларга яраткан мәгълүм кисәтүне халык, җитәкчеләр ишеткән тәкъдирдә без бүген гел башка халәттә буласы идек тә бит…

Таңсылу Галимова

ТАТАРСТАН КҮПЕРЕ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Яз көне Рөстәм Миңнеханов Таҗикстанда булды. Биредә ул ил Президенты Эмомали Рахмон белән дә очрашты. Былтыр ике арада товар әйләнеше 30,7 миллион доллар тәшкил иткән. Алдагы ел белән чагыштырганда, әлеге күрсәткеч 57 процентка үскән. Хезмәттәшлекне ныгыту өчен мөмкинлекләр күп. Эмомали Рахмон сәүдә-икътисадый һәм гуманитар бәйләнешларны үстерүгә уңай караш җиткерде. Ил Премьер-министры Кохир Рәсүлзәдә белән очрашу барышында яклар бергәләп эшләү өчен өстенлекле юнәлешләр арасында машина төзелеше, авыл хуҗалыгы, сәламәтлек саклау һәм мәгълүматлаштыру тармакларын билгеләп үтте.

Апрель башында Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге Татарстан делегациясен Минскида Белоруссия Президенты Александр Лукашенко җылы каршы алды.

– Без күп еллар таныш, чын дуслар. Мин сезнең төбәкнең үсешен инде күптән кызыксынып күзәтәм. Ирешкән уңышлар сокландыра һәм безне Казан белән тагын да тырышыбрак эшләргә рухландыра, – диде Александр Лукашенко.

Аның әйтүенчә, Татарстан җире Беларусь Республикасына бик тә охшаган. «Әгәр самолетта Татарстан өстеннән очуыңны белмәсәң, бу нәкъ безнең Беларусь табигате дип уйлар идең», – дип белдерде ул.

2022 елда Татарстан белән Белоруссия арасында тышкы товар әйләнеше 817 миллион доллардан артып киткән. Александр Лукашенко әлеге күрсәткечне 2 миллиард долларга җиткерү өчен бөтен шартлар булуын әйтте.

Эш арбасы тәгәрмәченә таяк тыгарга теләүчеләр дә бар. Билгеле булганча, Молдовага эш сәфәре белән барган Рөстәм Миңнеханов Кишинев аэропортыннан кире борылып кайтырга мәҗбүр булды. Биредә ул «Халыклар дуслыгы – 2023» I Халыкара халыклар дипломатиясе конгрессында катнашырга тиеш иде. Татарстан Рәисен «күрергә теләмәгән зат» дип атадылар һәм ил чиген узарга рөхсәт итмәделәр.

– Америка Татарстан Рәисен санкцияләр исемлегенә кертте. Шуңа күрә хәзер Рөстәм Миңнехановка каршы административ чаралар күрәләр. Без моңарчы халыкара кануннар гамәлдә булган, алар үтәлгән җәмгыятьтә яшәдек. Бүген исә бу халыкара кануннар барысы да юкка чыгарылды. Тотрыклылыкның нигезе бетерелде. Миллионлаган кешенең тынычлык, киләчәккә ышанычы нәкъ менә Америка тарафыннан юкка чыгарыла, – диде бу уңайдан танылган сәясәт белгече Марат Бәширов «ВТ» хәбәрчесенә.

tatarstan.ru

Хәзерге кебек катлаулы шартларда хезмәттәшлекне ныгыту турында Татарстан Рәисе Үзбәкстанда бу ил Президенты Шәүкәт Мирзиёев белән очрашуда әйтте. Моннан бер ел элек Ташкент өлкәсендә ачылган «Чирчик» технопаркы кебек уртак проектларның нәтиҗәлелеген Шәүкәт Мирзиёев та билгеләп үтте. Узган ел Татарстан белән Үзбәкстан арасында товар әйләнеше 290 миллион доллардан артып киткән. Үсеш 50 процент тәшкил иткән. Сүз уңаеннан, эш сәфәре барышында Үзбәкстанның Җизак шәһәрендә яңа технопарк ачылды.

Май аенда Татарстан Рәисе Шанхайга барды. Татарстанның Кытай провинцияләре белән 7 килешүе бар. Пекинда республиканың сәүдә-икътисадый вәкиллеге эшли. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстан һәм Кытай арасында товар әйләнеше ел саен арта. Узган ел нәтиҗәләре буенча ул 58 процентка үскән һәм 1,6 миллиард доллардан да артып киткән.

Рәис чит илдә Сабан туенда да катнашты. Азәрбайҗанга эш сәфәре барышында Рәис милләттәшләребезне сәламләде. Соңгы мәгълүматларга караганда, Азәрбайҗанда 27 меңнән артык татар яши. Былтыр ике арада товар әйләнеше 125 миллион доллардан артып киткән. Чит илгә эш сәфәре кысасында, Рөстәм Миңнеханов һәм Азәрбайҗан Президенты Илһам Алиев «КАМАЗ» белән Ганҗә автомобиль заводы катнашында төзелгән яңа сервис үзәген ачуда катнаштылар.

Рөстәм Миңнеханов «KazanForum»га килгән дистәләгән ил вәкиле белән очрашты. Петербург халыкара икътисады форумында да эшлекле күрешүләр булды. Бүген Татарстанның чит илләргә салган күперләренең ныклыгына шик тә юк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Антон КОБЯКОВ, Россия Президенты киңәшчесе:
– Казан – илнең иң нык үсеш алган һәм уңайлы шәһәрләреннән берсе. БРИКС илләре дәүләтләре башлыклары очрашуы – зур, амбициоз һәм системалы чара. Россия аны югары дәрәҗәдә оештырырга һәм үткәрергә тиеш. Без БРИКС илләре бишлеге һәм безгә дустанә илләр-хезмәттәшләр йөзендә халыкара җәмәгатьчелек белән әңгәмә коруны дәвам иттерәчәкбез. Сәүдәдән алып куркынычсызлыкка кадәр – барлык юнәлешләр буенча сөйләшүләр алып барачакбыз.

Аңлашу турында сөйләшу

Мәскәүдә Милләтара мөнәсәбәтләр һәм дини берләшмәләр белән берлектә эшләү буенча совет утырышы булды. Аны Федерация советы Рәисе урынбасары, Совет рәисе Константин Косачев уздырды. Видеоконференц-элемтә режимында үткәрелгән утырышта Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Милләтара мөнәсәбәтләр һәм дини берләшмәләр белән берлектә эшләү советы рәисе урынбасары Фәрит Мөхәммәтшин катнашты.

Республика парламенты башлыгы фикеренчә, Россиядә традицион кыйммәтләрне ныгытуда күпмилләтле халыкның нигезен тәшкил итүче традицияләр һәм гореф-гадәтләрне саклау, үстерү зур роль уйный.

– Без Татарстанда Россия Президенты Указы белән расланган «Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм ныгыту буенча дәүләт сәясәте нигезләре»н кабул итүне хупладык, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин. – Бу документта шулай ук безнең күпмилләтле республикабызны борчып килүче барлык мәсьәләләр дә күздә тотылган.

Парламент башлыгы искәртүенчә, Татарстан Республикасы төрки, славян, фин-угыр халыкларын, ислам һәм христиан цивилизациясен, әхлакый башлангычларын берләштерә. «Күп гасырлардан бирле толерантлык традицияләре, бер-беребезнең ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен аңлау, үзара ихтирам һәм ышану хисләре сакланып килә. Күпмилләтле Татарстан өчен төп кыйммәтләр бу», – дип басым ясап әйтте Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Советы Рәисе, гражданлык җәмгыяте институтлары, аерым алганда, Татарстан Халыклар ассамблеясы эше бик мөһим булып кала, диде. «Киң җәмәгатьчелек катнашында даими үткәрелеп килүче чаралар кешеләрнең үз тамырларын, әти-әниләре телен белергә, ата-бабалары традицияләрен лаеклы дәвам итәргә теләүләрен күрсәтә», – диде ул.

Традицион гаилә кыйммәтләрен саклау һәм ныгытуга аерым тукталып, Фәрит Мөхәммәтшин: «Минемчә, гаилә кыйммәтләрен пропагандалау күбрәк игътибар таләп итә. Әхлак нигезләре башта – гаиләдә, аннан соң мәктәпләр һәм уку йортларында салына», – диде.

Фәрит Мөхәммәтшин тәкъдиме рекомендацияләрдә исәпкә алыначак. Алар утырыш йомгаклары буенча дәүләт хакимияте органнарына юлланачак.

Теманың дәвамы 3 нче биттә >

Уртак бәйрәм

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

– Кемдер, узган ел мул уңыш алырга безгә һава торышы ярдәм итте, дип уйлый икән, ялгыша. Бу – соңгы елларда без бергәләп системалы кабул ителгән карарлар нәтиҗәсе, – диде ул.

Аерым алганда, Дмитрий Патрушев әйтүенчә, туфракка күпләп ашлама кертү, авыл хуҗалыгы техникасын яңарту, чәчү мәйданнарын планлаштыру, дәүләт программалары, мелиорация үз нәтиҗәсен биргән. Шул ук вакытта әлегә чит илгә дә бәйлелек бар. Әйтик, үсемлекләрне саклау чараларының 72 проценты үзебезнеке булса, 28 процентын чит илләрдән алып кайтырга туры килә.

Министр әлеге вакытта Россиядә урып-җыю актив рәвештә алып барылганлыгын әйтте.

– Бүген 16 төбәктә 6 млн тоннадан артык ашлык җыеп алдык. Барысы да план буенча бара. Барлык аграрийлар да матди-техник база белән тәэмин ителгән, – диде ул.

Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, мондый төр чаралар агросәнәгать комплексы белгечләрендә кызыксыну уята.

– Бүген авыл хуҗалыгы тармагы – заманча һәм югары технологияле өлкә. Татарстан Республикасы – лидерларның берсе. Без авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү буенча Идел буе округында – беренче, ил күләмендә бишенче урында торабыз. Сөт, бәрәңге җитештерүдә алда барабыз. Ит, йомырка, ашлык, шикәр чөгендере буенча да уңышларыбыз яхшы, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Республика Рәисе быелгы чәчү кампаниясен уңышлы тәмамлауга басым ясады.

– Без бүген үзебезнең һәм башка төбәкләрнең селекция белән ни дәрәҗәдә җитди шөгыльләнүләрен күрдек. Республикада 50 орлык җитештерү хуҗалыгы һәм дүрт орлык заводы эшли. Алга таба студентлар белән эшләүгә зуррак игътибар бирергә кирәк, – диде ул.

Республика бюджетыннан ел саен ашлама сатып алыр өчен 1 млрд сумнан артыграк акча бүлеп бирелүен әйтте.

– Быел имин ел түгел, ләкин аңа карамастан, без терлекчелек һәм үсемлекчелек өчен мөһим булган мәсьәләләрне хәл итүгә бөтен көчебезне куячакбыз, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Монда, әлбәттә, мелиорациягә зур игътибар бирергә кирәк. Ел саен бу максатларга 450 млн сум акча бүлеп бирәбез. 5 елда 6 млрд сумнан күбрәк акча тотылды. Һәм бүген республикада сугарыла торган җирләр 34 мең гектарны тәшкил итә. Бу гына җитми. Шул ук вакытта 2010 ел безне яшелчәләрне сугарырга өйрәтте. Шуңа күрә республиканы яшелчәләр белән тәэмин итүдә бернинди дә куркыныч юк.

ЛӘМ БАСУЫНДА ЧӘЧӘК ҮСӘЧӘК

Дәүләт Советында

Казандагы юынтык сулар кая китә? Су торбаларыннан агып килгән, ахыр чиктә ләмгә әйләнгән калдыклардан файда ясап буламы? Бу сулар зур елгаларга нинди зыян сала? Татарстан депутатлары, әнә шул сорауларга җавап эзләп, Казан читендәге ләм басуларына чыкты. Берочтан су чистарткыч биологик корылмаларның торышын да күреп кайттылар.

Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты һәм комитет каршындагы Экспертлар советы күчмә утырыш үткәрделәр. Депутатлар Татарстанда «Иделне сәламәтләндерү» илкүләм проектын гамәлгә ашыру мәсьәләләре турында сөйләштеләр. Республиканың Экологик һәм Җир кодексына, шулай ук органик продукция җитештерүне үстерү һәм ветеринария эше турындагы республика законнарына үзгәрешләр кертү турындагы закон проектларын карадылар.

Без – журналистлар да бу җирләрне күреп кайттык. Монда эшләр кызу бара. Биредә 2021 елдан бирле ләм киптерәләр. Аннан киләчәктә кулланырга яраклы продукт алмакчы булалар. Подрядчы оешма җитәкчесе, быелга дигән эшләрнең 60 проценты башкарылды инде, ди. Хәзерге вакытта алар ләм кырларын рекультивацияләү белән мәшгуль.

– Безнең максат – Иделгә эләгүче юынтык суларны чистарту. Статистика буенча, зур шәһәрләрнең чистарту корылмаларының бик аз проценты гына санитар нормаларга туры килә. Казандагы чистарту корылмаларын реконструкцияләү проектының беренчесе – быел, икенче өлеше 2024 елда тәмамланыр дип көтәбез, – диде Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе Азат Хамаев. – Ләм басуларын эшкәртүгә дәүләттән 7,5 млрд сум акча бирелде. Чистарту корылмаларына тотыласы акча да шундый ук суммада.

«Ядранстрой» оешмасы ләм басуларын бетерәчәк һәм су чистарту корылмаларын төзеячәк. Оешманың генераль директоры Марат Хәйруллин 2024 елда ләм басулары бөтенләй бетәр дип ышандыра. Ул урыннарда агач утыртырга яки чәчәк үстерергә мөмкин булачак.

– Шактый эшләр башкарылды. Бер тәртипкә салынгач, эш тиз бара. Кыенлыклар да юк түгел. Санкцияләр кертелгәч, кайбер җиһазларны таба алмадык. Әмма эшне туктатмадык, Россиядә җитештерелгәнен таптык, үзебез дә әллә ниләр уйлап чыгардык, – ди ул.

«Иделне сәламәтләндерү» илкүләм проекты ярдәме белән суга баткан корабларны да чыгармакчылар. Бу хакта Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Егор Тарнавский сөйләде.



tatarstan.ru

– Мондый кораблар елгага зур зыян сала һәм куркыныч тудыра. Россия Табигать министрлыгы баткан корабларны күтәрү буенча безнең пилот проектны хуплады, объектларның өстенлекле исемлеген билгеләде. Әлегә Россиянең диңгез һәм елга флоты техник документация әзерли. Суд карары буенча су төбеннән 75 объект күтәрелергә тиеш, – ди ул.

Министр урынбасары, сулар пычрануның төп сәбәпчесе авыл хуҗалыгы оешмалары, диде. Аның әйтүенчә, терлекчелек фермаларыннан сулыкларга калдыклар агып ята.

– Моны булдырмас өчен тирес саклау өчен махсус лагуналар төзергә кирәк. Шулай ук яр буйлап саклагыч урман полосалары булдыру да – нәтиҗәле ысул. Татарстан территориясендә саклагыч урман полосаларын булдыру буенча пилот проект Россия Табигать министрлыгы тарафыннан хупланды, – диде Егор Тарнавский.

Комитет утырышында Татарстанның Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында закон проекты каралды. Хәзер зур бакланны ау ресурсларына кертәчәкләр. Татарстанның Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын саклау идарәсе җитәкчесе Ринат Чиспияков әйтүенчә, соңгы вакытта безнең сулыкларда балыкларга зур зыян китерә торган баклан үрчегән. «Балыклар бөтенләй кимеп беткәнче, чара күрсәк иде», – диде ул. Депутатлар бакланны ауларга рөхсәт бирергә дигән карар кабул иттеләр. Шулай итеп әлеге хәлне җайга салмакчылар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

«Иделне сәламәтләндерү» илкүләм проекты республиканың экологик хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән. Татарстанда **2024** елга кадәр бу проектны финанслау күләме **22,3** млрд сумны тәшкил итә. Шуның **15,5** млрд сумы федераль бюджеттан бүленеп бирелгән. Иделне саклар өчен 13 биологик чистарту корылмасы төзергә һәм елгага куркыныч ясаучы ике объектны сүтеп ташларга кирәк.

ӨЙДӘ БУРАН БУЛМАСЫН

8 июль – Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне

Бәхетле гаилә нигезе – сабырлык. Азнакай районының Тымытык авылында яшәүче Ләйсән һәм Фәрит Шәяхмәтовлар бертавыштан шулай ди. Сабырлыкны юлдаш иткән бәхетле пар инде унсигез ел иңне иңгә куеп гомер итә. Тупырдап торган алты балалары үсеп килә аларның. Быел Шәяхмәтовлар гаиләсе өчен аеруча шатлыклы булды. Кадерле әниләре Ләйсән Татарстанның «Ана даны» медале белән бүләкләнде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Ләбибә һәм Рәкыйп Нигъмәтуллиннар 58 ел иңне иңгә куеп гомер итә.

– Бу бүләккә бездән бигрәк балалар сөенде инде. Шатлыклы да, шул ук вакытта бик зур җаваплылык та өсти торган дәрәҗәле медаль бу. Күп бала анасы булырмын дип күз алдына да китермәгән идем. Үзебез гаиләдә алты бала үстек. Һәр бала үз ризыгы белән туа. Берсе янына икенчесе сыя. Бер-берсенә иптәш булып, бергәбергә үсәләр. Шуңа күрә күп бала алып кайтудан куркырга кирәкми. Балалар бөтен хуҗалык, бакча эшләрендә булыша. Маллар тотмыйбыз. Гараж, сарай күтәрдек. Бу эшләрне барың бербөтен булганда гына башкарып чыгарга мөмкин, – ди Ләйсән.

Дүрт малай һәм ике кыз тәрбияли Шәяхмәтовлар. Олы уллары Вилданга – 16 яшь. Быел ул Әлмәт политехник техникумының беренче курсын тәмамлаган. Уллары Данил белән кызлары Эльвина – мәктәп укучылары. Самир белән Айлида балалар бакчасына йөриләр. Кечкенә уллары Элвинга әле 1 яшь тә 3 ай гына. Ләйсән әлегә бала ялында. Аңа кадәр шәхси сак оешмасында эшләгән. Ире Азнакайның бер оешмасында мастер булып хезмәт куя.

Фәрит белән бер авылдан – күрше урамнарда яшәп, бер мәктәптә укып, бергә уйнап үскән алар. Унынчы сыйныфта укыганда Ләйсән авыл клубында узган бәйрәмдә Кар кызы булып уйный. Кыш бабай ролен исә Фәрит башкара. Шушы көннән аларның дуслыгы мәхәббәткә әверелә дә куя. Хәзер инде егерме елга якын тормыш сәхнәсеннән бергә атлый алар.

– Ирем сүзгә дә, эшкә дә оста булып чыкты, Аллаһка шөкер. Гаилә бәхете өчен ир-ат та, хатын-кыз да бер үк дәрәҗәдә тырышырга тиеш. Бер-берсенә терәк булып, юл куеп, сабыр һәм бердәм булып яшәгән парлар гына бәхетле буладыр ул, – ди Ләйсән. – Өйдә савыт-саба шалтырамыйча тормый, билгеле. Үпкәләшсәк, мин атналар буе эндәшмичә йөри алам. Андый чакта ирем беренче сүз башлый. Әнә шулай бер-береңә юл куя белергә дә кирәк шул. Әбием белән бабам 63 ел бергә гомер итәләр. Шулар кебек тигез, бәхетле тормышта яшәсәк иде, бергә-бергә олыгайсак иде, дип телим.

Яшьләргә үрнәк булырлык тагын бер шундый соклангыч пар Кукмара районының Вахит авылында яши. Ләбибә апа белән Рәкыйп абый Нигъмәтуллиннарның бергә гомер итүләренә быел 58 ел тулган.

– Алтмыш елга якын гомер алты көн кебек кенә үтте дә китте. Аллаһка шөкер, бик матур яшәдек. Рәкыйбем бик тырыш, ышанычлы кеше булып чыкты. Эчмәде, тартмады. Гомер буе комбайнда эшләде. Гел алдынгылар рәтендә йөрде. 81 яшьтә булуына карамастан, әле бүген дә бер урында утырып тора алмый – йорт тирәсендәге бөтен эшләрне тәртипләп, эшләп тора, – ди Ләбибә апа.

Тормышыннан чын күңелдән канәгать икәне һәр сүзеннән, һәр ымыннан сизелә Ләбибә апаның. 19 яшендә Аман-Оштырма авылыннан Вахитка укытырга килгән җиреннән шушы авылның килененә әверелеп куя ул. Рәкыйп абый белән лачындай өч егет үстерә алар.

– Мин килгәндә, өйдә каенанам белән иремнең апасы да бар иде. Шуңа күрә, шаярып, ике каенана белән тордым, дим. Бергә 38 ел матур-тату яшәдек, Аллаһка шөкер. Сүзгә килмәдек, бер-беребезне аңлап яшәдек. Каенанам бик акыллы кеше иде. Балалар үстергәндә дә зур терәк булды. Алар безгә үрнәк булып яшәде. Хәзер инде без үзебез – балаларга, оныкларга үрнәк, – дип хатирәләргә бирелде Ләбибә апа.

Ләбибә апа әле үзе дә кызлар кебек. Без шалтыратканда бакча тирәсендә әвәрә килеп йөри иде.

– Киленем җәйге ялга чыкты да, мин дә ялга чыктым, – дип көлеп җибәрде ул. – Әни, эшләмә, ял ит, дип кенә тора. Бөтен эшне бергә-бергә башкарабыз. Өч киленем бар. Өчесеннән дә уңдым. Кызларым кебек бик якын алар миңа. Алар турында бер сөйли башласам, туктый алмыйм. Моны ишеткәч, күпләр: «Әйе, сиңа гына шундый киленнәр эләккәндер инде», – диләр. Эләкте шул, Аллаһка шөкер. Бу сүзләрне чын күңелемнән әйтәм. Алга таба да бергә-бергә матур итеп яшәргә язсын.

Елларда Ләбибә апа белән Рәкыйп абыйның барлык балалары, оныклары төп нигезгә җыела. Барысы бергә 29 кеше булалар икән. Эштә дә, ялда да бергә алар. Бу урында Ләбибә ападан шундый күркәм гаилә булып яшәүнең төп сере турында сорарга ашыгам. Ул исә, бәхетле гаиләнең ачкычы – хатын-кыз кулында, ди.

– Гаиләдә күп нәрсә хатын-кыздан тора. Ир-ат, нинди генә көчле булса да, гомер буе бала белән бер бит ул. Шуңа күрә хатын-кызга аны да, янәшәдәгеләрне дә көйләп яшәргә туры килә. Әнә шушы бурыч төгәл үтәлсә, гаилә бәхетле була да инде, – ди Ләбибә апа.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Иң кадерле урын

Татарстан Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы Гөлшат НИГЪМӘТУЛЛИНА бәйрәм белән котлады.

«Бу көн буыннан буынга күчеп килүче гаилә кыйммәтләрен саклау, никах институтын ныгыту, балалар тәрбияләүдә ата-аналарның җаваплылыгын үстерү һәм күпбалалы булуның асылын һәм әһәмиятен танытуга багышланган.

Бүгенге якты һәм шатлыклы бәйрәм зур рухи-әхлакый мәгънәгә ия, ул никах һәм гаиләнең «мәхәббәт һәм тугрылык» исемле мәңгелек кыйммәтләрен символлаштыра, – диелә аның котлавында. – Гаилә – һәркем өчен иң кадерле урын. Монда бер-беребезне яратырга һәм хөрмәт итәргә өйрәнәбез, якыннарыбыз һәм туганнарыбыз турында кайгыртабыз, авырлыкларны җиңеп чыгарга көч табабыз, шатлыкларны уртаклашып яшибез.

Татарстан Министрлар Кабинетының ГХАТ идарәсе һәм шәхсән үз исемемнән барлык татарстанлыларны бәйрәм белән чын күңелдән котлыйм! Һәрбер гаиләдә мәхәббәт, хөрмәт, матур һәм җылы мөнәсәбәтләр, иминлек яшәсен. Өйләрегездә балалар, оныклар тавышы яңгырасын! Бәхетле булыгыз!»

«КӨЙЧЕ» VS КОМПОЗИТОР:

БЕЗГӘ КАЙСЫ КИРӘГРӘК?

Оясыннан очыргач та ташлыйсы түгел! Татарстан Парламентының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты утырышында яңгыраган төп фикер шушы булды. Сүз композиторлар турында бара. Көчле сәнгать мәктәпләребез була торып та, профессиональ композиторларыбыз коточкыч аз. «Көйче»ләргә дә бер юнәлеш бирәсе иде. Бу проблемаларны ничек хәл итә алабыз соң?

Айрат Зарипов җитәкләүче комитет утырышында каралган төп мәсьәләләрнең берсе Татарстанда өстәмә белем бирү өлкәсенә кагылышлы иде. Бүген республикада 144 сәнгать мәктәбе бар. Әлеге өстәмә белем бирү йортларында җәмгысы 4,5 мең остаз укыта.

– 2021 елда безнең республика балалар сәнгать мәктәпләре саны буенча Россия күләмендә бишенче урында иде. Балаларны мондый белем белән тәэмин итүгә килгәндә, әлеге күрсәткеч 9,2 процентны тәшкил итә, бу Россиядәге уртача күрсәткечләрдән югарырак, – дип сөйләде Татарстан мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Әдһәмова.

«Мәдәният» илкүләм проекты кысасында 2020 елда – 11, 2022 елда 14 сәнгать мәктәбенә инструментлар, җиһазлар һәм уку материаллары алынган. Киләсе елга тагын 14 мәктәпне шул рәвешле «баетырга» ниятлиләр. Моннан тыш, бу максатларга республика бюджетыннан да акча бүленеп бирелә. Әйтик, 2022 елда җәмгысы 30 гөслә, 34 гармун, 28 думбра, 90 балалайка һәм 90 курай алынган.

Саннар телендә сөйләшүебез юкка түгел: кечкенәдән күңеле сәнгатькә тартылганнарга Татарстанда мөмкинлекләр җитәрлек ул үзе. Музыка сәнгатен аерым карасак, өметле һәм сәләтле балалар да байтак. Ләкин профессиональ музыкантлар әзерлибез икән, аларны җиде юл чатында ташлап калдырмыйча, озата барырга да кирәк. Югыйсә берничә елдан бөтенләй композиторларсыз калабыз. Татарстан Дәүләт Советы депутаты Рамил Төхвәтуллин әнә шулай дип белдерде.

– Бүген композитор төшенчәсе бөтенләй үз мәгънәсен югалтты. Билгеле, бөтен эстрада кырын контрольдә тоту авыррак булыр. Әмма ниндидер юнәлеш булырга тиеш. Бездә профессиональ композиторлар ничәү? Санасаң, бер кул да җитә бит. Сүз дә юк, алар йөз үк тә була алмый. Кадрлар юнәлешендә эшләргә кирәк. 5 елдан, 10 елдан ничә композиторыбыз булыр? Мәдәният министрлыгы бу мәсьәләгә җитдирәк карарга тиеш. Хәзер контрольгә алмасак, киләчәк өметле була алмый, – диде ул.

Аның сүзләрен Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла да куәтләде:

– Әлбәттә, Эльмир Низамов – бөек композитор. Без барыбыз да аңа карап торабыз. Ләкин шул ук Рөстәм Яхин, Нәҗип Җиһановны алсак, алар бит зур күләмле әсәрләр белән беррәттән җырлар да иҗат иткән, һәм халык ул җырларны рәхәтләнеп җырлаган. Ә бүгенге композиторлар, зур күләмле әсәр язса, җыр яза алмый, җыр язса, күләмле әсәр яза алмый. Җыр язучыларның күбесе нота да белми, шуңа аларны композитор түгел, көйчеләр дип атасаң, хәерлерәк булыр. Ә профессионаллар арасында көндәшлек юк. Безнең бит әле Композиторлар берлеге дә бар. Аларның эшчәнлегендә шушы юнәлештә ниндидер бер алгарыш күрмим. Аннан соң, без менә зур язучыларның юбилейларын үткәрәбез. Мәшһүр композиторларыбызны да зурларга кирәк, яшьләр өчен өлге бит алар, – диде.

Аннан соң композиторлар мәктәбе турында сүз чыкты. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, Ркаил Зәйдуллага, уены-чыны белән бергә: «Өйрәтүен өйрәтәсең, ә әдәбиятчылар өчен андый мәктәп бармы соң?» – диде.

Татар музыка сәнгате турындагы сөйләшүләр һәрвакытта да үз нәтиҗәсен бирми шул, кызганыч. Эстрада «кыр»ын чистартырга, музыкаль театр ачарга кирәк кебек сүзләр дә шактый яңгырады. Безгә исә, үкенечкә калмасын, дип, ышанасы һәм көтәсе генә кала.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Фикер

Зөфәр ХӘЙРЕТДИНОВ,
Татарстанның халык артисты, җырчы-композитор:

– Композиторлык – ул, гомумән, бик авыр һөнәр. Җыр язу белән бутамаска кирәк. Чын композитор булу өчен консерваториядә укып, профессиональ белем алу зарур. Бездә, кызганыч, профессиональ композиторлар бик аз. Әйтик, мин Эльмир Низамов һәм Миләүшә Хәйруллинаны гына атый алам. Ә эстрада жанрында иҗат итүчеләр, киресенчә, артыгы белән күп. Шунысы борчый: аларның күпчелегенең музыкаль белеме бөтенләй юк, нота белмәүчеләр дә җыр яза бүген.

Профессиональ музыка сәнгатенә әйләнеп кайтсак, бу юнәлешкә Мәдәният министрлыгының игътибары җитми. Хәзерге вакытта югары сәнгать әсәре иҗат итеп, аны зур сәхнәдә тамашачыга тәкъдим итү – гаять катлаулы эш. Хөкүмәт, аерым алганда, Мәдәният министрлыгы ярдәм итмичә генә башкарып чыгарырдай түгел. Миңа калса, менә бу да яшьләргә профессиональ әсәрләр иҗат итәргә зур гына киртәләр тудырадыр.

«Татар-информ»

КОТЛЫЙБЫЗ!

Гаилә институтын ныгытудагы һәм балалар тәрбияләүдәге казанышлары өчен Татарстан Республикасының Зеленодольск районы Октябрь поселогыннан унөч баланың ата-анасы **Елизаров** Евгений Геннадьевич, **Елизарова** Екатерина Николаевна **Татарстан Республикасының «Ата-ана фидакарьлеге» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Азнакай муниципаль районы буенча Азнакай шәһәреннән алты бала анасы (аларның бишесе өч яшькә җиткән) **Рәхимова** Олеся Марат кызы, Актаныш муниципаль районы буенча Яңа Балтач авылыннан биш бала анасы **Бакирова** Гөлфия Вазыйхҗан кызы, Чүпрәле муниципаль районы буенча Шланга авылыннан биш бала анасы **Кәримуллина** Фәния Адиҗан кызы, Мамадыш муниципаль районы буенча Мамадыш шәһәреннән сигез бала анасы **Камалова** Эльмира Ибраһим кызы **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүдәге казанышлары, милли көрәшне популярлаштыруга зур өлеш кертүе өчен «Әхмәтҗанов Фәйзелхан Гарифҗан улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы, «Татарстан Республикасы Көрәш федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президиумы әгъзасы **Әхмәтҗанов** Фәйзелхан Гарифҗан улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Һөнәри эшчәнлектә югары казанышларга ирешүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционер җәмгыяте генераль директорының куркынычсызлык һәм башкарма хакимият органнары белән эшчәнлекне координацияләү буенча киңәшчесе **Гатин** Илһам Инсаф улы, республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «АЛГА» колхозы рәисе (Татарстан Республикасының Алексеевск районы) **Хамматов** Тәлгать Рифгать улы, республиканың агросәнәгать комплексына квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстанның агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институты» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе баш фәнни хезмәткәре **Якушкин** Николай Михайлович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Биектау районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Айбаш ветеринария участогы ветеринария табибы – мөдире Абдуллин Рәис Илдар улына, «Сарман районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Саклаубаш ветеринария участогы ветеринария табибы – мөдире Хаҗиев Зөфәр Нури улына, «Хайваннар сәламәтлеген саклау федераль үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе Татарстан сынау лабораториясенең серология һәм лептоспироза бүлеге мөдире **Хакимова** Рамилә Наил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Новая Заря» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең терлек караучысы (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Әхмәтҗанов** Рәис Хәсән улына, «Яңа тормыш» акционер җәмгыяте сыер савучысы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Закирова** Раушания Зәки кызына, «Хәмит Мөстәкыймов исемендәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Ихсанова** Резеда Мөнир кызына, «АЛГА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Мадиярова** Әлфия Рәис кызына, «Сасна» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Нәҗипова** Нурания Хуҗи кызына, «Таллы Бүләк» авыл хуҗалыгы производство кооперативының терлекләрне ясалма орлыкландыручысы (Татарстан Республикасының Азнакай районы) **Фатыйхова** Гөлчирә Габдерәуф кызына, «Бакырчы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте терлекчесе (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Хисамов** Харис Фәннур улына, «Нур» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең машина белән сыер саву операторы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Хөсәенова** Гөлсинә Нәсим кызына, «Апас-мол» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең «Шыгай» товарлыклы-сөтчелек фермасы терлекчесе (бозау караучысы) (Татарстан Республикасының Апас районы) **Шәрәфиева** Илүзә Ревер кызына **«Татарстан Республикасының атказанган терлекчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Хузангай» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Әлки районы) **Әхмәтсафин** Илгиз Ислам улына, «Нур» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте механизаторы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Гаттаров** Хавил Мирзашәех улына, «Актаныш» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең авыл хуҗалыгы производствосы тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Гафуров** Нияз Роберт улына, «Нармонка» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчы-машинисты (Татарстан Республикасының Лаеш районы) **Творогов** Владимир Геннадьевичка, «Ярыш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Әлмәт районы) **Хәйруллин** Рамил Рәмис улына, «Саф» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Шәрифҗанов** Булат Әбүзәр улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе финанс-икътисад бүлеге башлыгы **Әнвәров** Илдар Зөфәр улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Буа муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитештерү бүлеге башлыгы **Дәүләтшин** Идрис Йосыф улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы **Кәримов** Рәхимҗан Зариф улына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе финанс-икътисад бүлеге башлыгы **Марнаутова** Наталья Владимировнага, «Ак Барс» холдинг компаниясе» акционер җәмгыятенең коммерция департаменты директоры урынбасары **Моратшин** Айрат Ринат улына, «Агроил» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Хәйруллов** Фәргать Мидхәт улына, «Чаллы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе баш бухгалтеры **Чикинова** Зәнфирә Шабан кызына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының хайваннар, үсемлекләр дөньясы һәм аеруча сакланыла торган табигать территорияләре өлкәсендә Биектау районы буенча дәүләт күзәтчелеге район (районара) бүлеге башлыгы **Дәүләтшин** Виталий Мифодьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган экологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык бишенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык бишенче утырышын 2023 елның 13 июлендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 6 июле
№ 2029-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык бишенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык бишенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 446-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
3. «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 443-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 419-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
5. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 441-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 442-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында җиңел таксида пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында» 451-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү турында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү турында» 436-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлегә турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 444-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 10^1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 445-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасы Экология кодексының 135 һәм 135^4 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 433-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 435-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 440-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 437-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 449-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 22 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы турында.
17. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 368355-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби бурычлылар белән хезмәт шартнамәсе төзегәндә, шулай ук хәрби исәпкә алу өлкәсе законнарындагы аерым хокук бозулар өчен җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә).
18. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 12.8 һәм 27.12^1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 379447-8 номерлы федераль закон проекты турында (аерым дару препаратларын кулланганда исерү халәтендә булган йөртүче транспорт чарасы белән идарә иткән өчен административ җаваплылыкны төгәлләштерү өлешендә).
19. «Россия Федерациясе Урман кодексының 74.1 статьясына үзгәреш кертү турында» 361140-8 номерлы федераль закон проекты хакында (санитария-сәламәтләндерү чараларын билгеләгәндә урман участогын арендалау шартнамәсенә үзгәрешләр кертү өчен нигезләрне төгәлләштерү өлешендә).
20. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{10} статьясына үзгәрешләр кертү турында» 361268-8 номерлы федераль закон проекты хакында (чикләрендә гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез бирү гамәлгә ашырыла торган территорияне билгеләү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).
21. «Хайваннарга карата җаваплы мөнәсәбәт турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чуваш Республикасы Дәүләт Советы закон чыгару инициативасы хакында.
22. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасы халкын транспорт белән тәэмин итү турында».
23. 2023 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 6 июле
№ 2030-VI ДС

Җәй хикмәтләре

Елан кешене тиз сизә

Көннәр эсселәнү белән, еланнар ешрак күренә башлады. Өй тирәләрендә, бакчаларында елан очратучылар шактый. Элек алар урманда, басу-кырларда гына иде. Авылга да печәнгә ияреп кенә кайталар иде. Ә хәзер еланнар йорт тирәсендә рәхәтләнеп йөри. Тик КФУ мөгаллиме, биология фәннәре кандидаты, герпетолог Илдар Хәйретдинов искәртүенчә, республикада еланнар саны артты дип әйтеп булмый.

– Татарстанда еланнарны өйрәнүче белгечләр бармак белән генә санарлык. Берәүнең дә күпме елан барлыгын исәпләп караганы юк. Шуңа күрә без аларны арткан яки кимегән дип әйтә алмыйбыз. Тузбаш елга бер тапкыр 10–15 йомырка сала. Кара елан бөтенләй бер ел бала тудырса, икенче елда ял итә. Кара еланның 5–10 баласы була. Әлбәттә, эсседә алар күренә. Күбрәк салкынча урыннарга һәм сулыклар янына баралар. Шуңа кешеләр аларны еш очрата. Әгәр салкынча, дымлы һава торышы булса, алар күренми дә, кешедән качып яшиләр. Кеше еланны сизгәнче, ул аны сизә. Җиргә басып килүләрен тоялар. Шунда ук качарга телиләр. Тузбаш шулай эшли дә, – ди герпетолог. – Ә менә кара елан кеше күрсә, холкын күрсәтә. Ысылдаган була. Үзенчә саклануы инде ул аның. Елан беркайчан да беренче булып зыян салмый. Күрүгә читкә китәргә, аңа тимәскә кирәк, тыныч кына торсаң, яныңнан узып китәчәк.

Диндә дә, зыян салмаса, еланга тимәскә кушалар. Халыкта йортка елан ияләшсә, аны йорт хуҗасы дип атау гадәте дә бар. Бу чынлап та шулаймы? Казанның «Өметлеләр» мәчете имамхатыйбы Алмаз Сафин бу дөрес сүз түгел ди.

– Кешегә җеннәр елан булып та күренергә мөмкин. Йортта елан зыян китерсә, аны үтерергә була. Дини китапларда да шулай язылган. Әгәр кеше намаз укып утырганда, янына чаян яки елан килсә, ул аларны үтерер өчен намаздан бүленә ала, диелә. Чакмый торган елан икән, андыйларны тотып, чыгарып җибәрергә кирәк.

ЕЛАН ЧАККАН ОЧРАКТА НИШЛӘРГӘ?

✓ Паника куптармыйча, хәрәкәтләнмичә тору яхшы.
✓ Иң элек яра кырыйларын кысып, агуын суырып түкерергә кирәк.
✓ 112 номерына шалтыратып ярдәм сорарга.
✓ Әгәр авыз эчегездә яралар булса, агуны суырырга ярамый.
✓ Яраны кисмәгез, марганцовка яки башка дарулар сөртмәгез.
✓ Күп итеп сыеклык эчегез.
✓ Елан чаккан урынга жгут салырга ярамый.
✓ Авыртуны басам дип, спиртлы эчемлек кулланмагыз.
✓ Аллергиягә каршы даруыгыз булса, шуны эчегез.
✓ Кичекмәстән хастаханәгә барып, организмга махсус сыворотка салдырырга кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

ТУГАН ИЛ БУЙЛАП

«Ефәк юлы – 2023»

Чили юлларын искә төшергән Татарстан, көндәшкә әверелгән тузан, җанатарлар алкышы. «Ефәк юлы» раллие ярышында катнашучылар җомга көнне Татарстандагы махсус участокны сынап, Уфага юл алды. 618 чакрымга сузылган беренче этапның 142 чакрымы Лаеш районының Державино авылында башланып, Мамадыш районының Катмыш авылында төгәлләнде. Беренче, көйсез юл. Раллида катнашучылар ярышның тәүге сынавында сынатмаганмы? Аларны Лаешта озатып, Мамадышта «ВТ» хәбәрчесе дә каршы алды.



«Лаеш халкы күнеккән»

Йөк машиналары, багги, мотоцикллар… Механиклар техника төзеклеген тикшерә, пилотлар күнекмәләр ясый, рухи яктан әзерләнә. Лаеш районының Державино авылында «Ефәк юлы»ның беренче ярыш көне башланды.

«Осталык таләп итәчәк». «Ефәк юлы» проекты җитәкчесе Владимир Чагин юлны әнә шулай бәяләде.

– Маршрут башында ук спортчыларны әйләнешләр, чокырлар, бормалы юллар көтәчәк. Катнашучыларга чын-чынлап машинаны тоемларга туры киләчәк, – дип аңлатты ул. – Командага аңлашырга, штурман белән уртак тел табарга кирәк булачак. Минемчә, шулай булганда, финишка уңышлы барып җитәргә мөмкин.

Финиш сызыгы исә – Мәскәүнең Кызыл мәйданында. Аңа кадәр раллида катнашучыларга төрле төбәкләрнең, аерым алганда, республиканың матур табигатенә хозурланырга мөмкинлек бар. Сүз уңаеннан, күп кенә узышчылар инде моңа игътибар иткән икән. «Тигез кыр гына түгел монда. Таулары да, сикәлтәләре дә бар. Бу участоктагы юл спортчыларга ярышка ияләшеп китү өчен бик яхшы булачак», – дип өстәде Владимир Чагин.

Тизлек дигәне автоузышчылар өчен генә түгел, раллида катнашучыларны кабул иткән районнар өчен дә мөһим ул. Лаеш районы башлыгы Илдус Зарипов ярышка күпме әзерләнүләрен әйтмәде. Бары тик:

– Безнең Лаеш халкы районнардагы мондый чараларга күнеккән инде. Без тиз арада оешып, тиз арада оештыра беләбез, – дип кенә җаваплады.

Татарстанның автомобиль спорты федерациясе башкарма директоры Рафаэль Баһаветдинов та маршрутның җиңелләрдән булмавын билгеләп үтте. «Мин әле үз машинамда юлны сынап кайткан идем. Бампер төшеп кала язды. Узышчыларның көрәшләре бар әле», – диде ул.

«Ефәк юлы»ның янә Казанга кайтуы да – шатлыклы вакыйга, дигән фикердә Рафаэль Баһаветдинов. «Зур ярышлар спорт үсешенә йогынты ясый. Балалар бар бит әле. Әйтик, картинг белән мавыгучылар. Акыллы, машинада йөри, ярыша белгәннәрне үстерү мөһим», – диде ул.

Халыкара чараларга безнекеләргә чик куюга карата да фикерен әйтте әңгәмәдәш. Истә булса, «КАМАЗ-Мастер» командасына сәяси сәбәпләр аркасында «Дакар» ралли рейдында катнашу тыелган иде.

– Минемчә, аларга бездән башка күңелсездер, – диде Рафаэль Баһаветдинов. – Алар гел үрнәк булдылар, аларга тиң булырга теләделәр. Спортта сәясәт булмаска тиеш, диләр, әмма бу гел алай түгел икән.

Старт алдыннан ярышта катнашучыларның кәефен белештек. «Таифмотоспорт» командасы белән баггида ярышучы Тимур Шиһабетдиновның кәефе күтәренке иде.

Узышта, иң мөһиме, игътибарлы булу, концентрацияне югалтмау». «Ефәк юлы» – җитди ярыш. Техниканы да тиешенчә әзерләдек, үзебез дә әзер кебек. Этап кысасында уза торган төбәкләрне беләбез. Юл сюрпризларсыз узар дип уйлыйм, – диде ул. – Эссе һава торышы үзенекен итә инде анысы. Барыбызга да, шул исәптән техникага да кызу. Әмма шартлар барыбыз өчен дә бер.

Шулай ук баггида ярышучы Сергей Карякин да ярышның яхшы узасына ышанычын белдерде. Татарстанда башкача була да алмый, диде ул.

– Кызык булачак, моңа шик юк. Татарстанда автоспортка кызыксыну зур булды, андый ярышларны яраталар, республика моның белән дан тота. Халык безне дә үз итәр, ә без яхшы нәтиҗә күрсәтә алырбыз дип уйлыйм, – диде ул старт алдыннан.

Кояш елмайды, тузан борчыды

Мамадышның Катмыш авылында Сабан туе диярсең. Аермасы шунда: милли бәйрәмдә халык кыр һәм көрәш батырларын зарыгып көтеп торса, монда – раллида ярыша торган экипажларны. Ихлас кызыксыналар, көтәләр, җан аталар, «Кайда безнең «КамАЗ»лар?» – диләр. Гадәттәгечә, озак көттермәделәр тагы. 142 чакрымлык махсус участокны беренче булып «МАЗ-СПОРТавто» командасыннан Алексей Вишневский узды. Шул ук командадан Сергей Вязович икенче урынны алды. «КАМАЗ-Мастер»дан Эдуард Николаев исә – өченче урында. 303 нче номерлы экипаж финиш сызыгын үтүе булды, машина тирәсен халык сырып алды. Бердән, машина яңа, моңа кадәр раллиларда катнашмаган төре. Икенчедән, халыкның пилот Эдуард Николаевны күрәсе килә, юл, команда хәлләрен сорашасы килә! Эдуард та хис-кичерешләрен тыймады, аралашты, фотога төште, малай-шалайның кызыксындырган сорауларына җавап бирде. «ВТ» хәбәрчесенә дә вакыт тапты. Танылган спортчы безне татарча сәламләде.

– Бу махсус участокны узуымнан әллә ни канәгать калдым, дип әйтә алмыйм. Эссе һава торышы үзенекен итте. Бөтен җир коры. Әйтик, көндәш янына да якын килерлек түгел, тузан күтәрелә. Төп көндәшебез тузан булды, – диде ул. – Беренче булып кузгалып киткәннәргә җиңелрәк булгандыр дип уйлыйм. Чөнки юл чиста иде. Тузан эчендә баруларыбыз Чилидагы махсус участокларны искә төшерде. Ралли-рейд бит инде бу шуңа да. Тузанмы, пычракмы – без барырга тиеш.

Эдуард, җанатарлар җылысын тоябыз, ди. «Тизлек буенча чикләүләр бар. Чөнки күп кенә участоклар халык яши торган җирләрдән уза. Без аларның җан атуын сизәбез. Балалар, әби-бабайлар, малайлар – барысы да кул чабып каршы алып тора», – диде ул.

Эдуард яңа техникага да бәя бирде. «Юлда үзен яхшы яктан гына күрсәтер дип уйлыйм. Сынатмас. Миңа исә команда белән булу күпкә мөһим», – диде ул.

Штурман Евгений Яковлев та тузаннан зарланды.

– Юл үзенчәлекле, кызыклы иде. Әллә ни авыр димәс идем. Махсус участок ярышлар өчен бик яраклы. Әмма тузан борчыды инде. Азмы-күпме җиле бар әле. Берничә көн коры һава торышы булу үзенекен итә шул. Йөк машиналары паровоз кебек барды дияргә була, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

…Владимир Чагинның да уенда – «КамАЗ» егетләре. Экипажлар бер-бер артлы финиш сызыгын үтә торды, ул һәркайсы янына килеп юл хакында сорашуын дәвам иттерде. Һәркайсына бер генә сүз: «Сынатмагыз!» Без дә шул теләктә!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

kamazmaster.ru

«КАМАЗ-Мастер»дан Эдуард Николаев экипажы Лаеш белән Мамадыш арасындагы махсус участок ярышын өченче булып тәмамлады.

СӘЙДӘ МӨХӘММӘТҖАНОВА:

«ХЫЯЛЫМ ТОРМЫШКА АША БАШЛАДЫ...»

Сәнгать дөньясында

Татар җыры, татар милләте өчен җан атучы яшь талант Сәйдә МӨХӘММӘТҖАНОВА соңгы арада яңалыклары белән сөендереп тора. Күптән түгел генә Әүхәдиев исемендәге музыка көллиятенең дипломлы белгече булган кыз зур хыялын тормышка ашырды – үз иҗади студиясен ачты. Сәйдә белән әнә шул турыда җәһәт кенә әңгәмә кордык.

:: Сәйдә, ни өчен үз студияңне ачарга булдың?

– Иҗат студиясен булдыру һәр яшь җырчының хыялы инде ул. Мин дә бу турыда хыялландым. Аллаһның рәхмәте һәм якын кардәшебез ярдәме белән шушы хыялым тормышка аша башлады.

:: Студия турында сөйлә әле. Анданиләр булачак?

– Студиягә килгәндә, ул өч өлештән тора: тавыш яздыру студиясе (аның хуҗасы – Искәндәр Мостафин), вокал дәресен бирә торган бүлмә һәм репетицияләр, иҗади очрашулар, кичәләр ясый торган зур зал, анда якынча 80 кеше утырта алабыз.

:: Вокал дәресләрен үзең дә бирәчәксеңме?

– Киләчәктә мин дә эшләрмен дип уйлыйм. Әлегә иҗади проектларым күп. Вокал дәресләре укытырга теләк белдерүчеләр булса, без бу бүлмәне, сәхнәне арендага бирәбез. Анда бөтен шартлар да бар. Инструменталь ансамбльләр дә репетиция ясый, шөгыльләнә ала.

:: Ачылыш кичәсе үзенчәлекле булган, ахры...

– Ачылыш кичәсе 25 июньдә булды. Беренче иҗади кичәне без Венера Гәрәевага багышларга булдык. Венера Хәсәновна – Татарстанның халык артисты, Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленең хормейстеры һәм минем остазым, хөрмәтле укытучым. Нәкъ 25 июньдә Венера апаның туган көне булырга тиеш иде, шуңа студиямнең шушы көндә ачылуы бик тә туры килде. Әлеге иҗади кичәмдә татар халык җырларыннан гына торган альбомны тәкъдим иттек, ул альбомны без Искәндәр абый Мостафин (композитор, аранжировкалар ясаучы, музыкант) тырышлыгы белән чыгардык. Ә инде Венера Хәсәновнаның васыяте буенча, без аларны иң элек классик рәвештә башкарырга тырыштык. Шул ук вакытта эстрада стилен дә кулландык. Альбомда 10 җыр тупланган һәм без шушы 10 җырга клиплар да төшерергә өлгердек, тиздән ТНВда күрә алачаксыз.

:: Син күптән түгел генә дипломлы белгеч булдың. Без сине ихластан котлыйбыз! Киләчәккә иҗади планнарың белән дә уртаклашсаң иде.

– Иҗади планнар шактый күп. Беренче чиратта, халык җырлары альбомын дәвам итәргә. Шулай ук танылган композитор Луиза Батыр-Болгари белән дә иҗатташлык дәвам итә, Луиза апа белән күбрәк тарихи җырлар иҗат итәбез. Искәндәр абый Мостафин белән үземнең автор җырларын булдырырга тырышачакбыз. Ә инде дөнья күрергә өлгергән яңа клипларны социаль челтәрләрдә, «YouTube»тагы каналымда карый аласыз.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5091 данә
Гомуми тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 296

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+